ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 14.12.2023 2023 **КАРАР**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә социаль өлкәдә муниципаль хезмәт күрсәтүләргә муниципаль социаль заказ формалаштырганда социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында

«Социаль өлкәдә дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүләргә дәүләт (муниципаль) социаль заказы турында» 2020 елның 13 июлендәге 189-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба - Федераль закон) 28 статьясындагы 3 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары (җирле үзидарә органнары) тарафыннан социаль өлкәдә дәүләт хезмәтләре күрсәтүне оештыру турында карарлар кабул итүгә гомуми таләпләрне раслау турында» 2020 елның 13 октябрендәге 1678 номерлы карары нигезендә Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Алабуга муниципаль районы территориясендә федераль закон нигезләмәләренә (1 нче кушымта) ярашлы рәвештә өстәмә белем бирү программаларын (сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәри программалардан тыш) (алга таба – социаль өлкәдә дәүләт хезмәтләре) гамәлгә ашыру» эшчәнлеге юнәлеше буенча социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештырырга.
2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Башкарма комитетын социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль социаль заказны раслаучы вәкаләтле орган итеп билгеләргә.
3. «Мәгариф» илкүләм проектының «Һәр баланың уңышы» федераль проекты чараларын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә

2023-2024 елларда балаларга өстәмә белем бирүне персональләштерелгән финанслау системасын кертү өлешендә социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль социаль заказны формалаштыру һәм башкару Федераль закон нигезендә әлеге карарның/күрсәтмәнең 1 пунктында күрсәтелгән эшчәнлек юнәлеше буенча социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләрне башкаручыларны Федераль законның 9 статьясы 2 өлеше 1 пунктында каралган сайлап алуның конкурентлык ысулын файдаланып башкарыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның 3 пунктында күрсәтелгән хезмәтләрне башкаручыларны сайлап алу ысулын куллану әлеге карарга 1 кушымта нигезендә билгеләнгән, социаль өлкәдә хезмәтләр башкаручылар тарафыннан кәрсәтелә торган муниципаль хезмәтләргә карата («балалар сәнгать мәктәбе», «балалар музыка мәктәбе», «балалар хор мәктәбе», «балалар сәнгать мәктәбе», «балалар хореография мәктәбе», «балалар театр мәктәбе», «балалар цирк мәктәбе», «балалар сәнгать һөнәрләре мәктәбе» махсус исемнәре булган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларыннан тыш) гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.
5. Расларга:

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру механизмнарын апробацияләү планын (2 кушымта).

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә «Өстәмә гомуми үсеш программаларын гамәлгә ашыру» муниципаль хезмәтен күрсәтүне оештыру механизмнарын апробацияләү кысаларында үткәрелә торган чараларны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләре таблицасын (3 кушымта).

Социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру буенча эшче төркем турында нигезләмәне (4 кушымта).

Социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру буенча эшче төркем составын (5 кушымта).

6. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруны мәгълүмати тәэмин итү тәртибен билгеләү максатларында билгеләргә:

вәкаләтле органнар, хезмәтләрне кулланучылар, хезмәтләрне башкаручылар, хезмәтләр башкаручыларны сайлап алуда катнашучылар, башка юридик һәм физик затлар арасында аларны алмашу электрон документлар формасында башкарыла торган документлар исемлеге:

социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль социаль заказ;

социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль социаль заказның үтәлеше турында хисап;

социаль сертификат нигезендә социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр башкаручылар реестрына кертүгә хезмәтләр башкаручының гаризасы;

муниципаль хезмәт алуга социаль сертификат нигезендә социаль өлкәдә муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) турында килешү;

социаль сертификат нигезендә «балалар өчен өстәмә гомуми үсеш программаларын гамәлгә ашыру» муниципаль хезмәтен күрсәтүгә хезмәтләрне кулланучының гаризасы (укуга кабул итү һәм социаль сертификат алу турында гариза);

«балалар өчен өстәмә гомуми үсеш программаларын гамәлгә ашыру» муниципаль хезмәтен алуга социаль сертификат;

балалар өчен өстәмә гомуми үсеш программаларын гамәлгә ашыру максатыннан хезмәтләр башкаручы һәм социаль сертификат алучы арасында төзелгән килешү;

социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру максатларында кулланыла торган дәүләт мәгълүмат системалары:

«Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасы;

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

«Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы өстәмә белем бирү навигаторы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы (алга таба – «Навигатор»);

төбәкләрдә учреждениеләр, программалар, өстәмә белем бирү чаралары һәм балаларны өстәмә белем белемгә җәлеп итүнең төп статистик күрсәткечләре буенча мәгълүмат җыю һәм анализлауның бердәм автоматлаштырылган мәгълүмат системасы (ӨБ буенча мәгълүмат системасы).

«Навигатор» кулланып формалаштырыла торган мәгълүмат һәм документлар исемлеге:

әлеге карарның 6.1 пункты 3-7 пунктларында каралган документлар;

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының норматив хокукый актларында каралган башка документлар һәм мәгълүмат.

7. Федераль законда формалаштыруы каралган мәгълүмат һәм документлар Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында Россия Финанс министрлыгының 2016 елның 28 декабрендәге 243н номерлы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә урнаштырылырга тиеш.
8. Әлеге карарның 6.1 пункты 1 пунктчасында каралган документны 2023 елда формалаштыру һәм раслау кәгазьдә гамәлгә ашырыла. Әлеге карарның 6.1 пункты 4 пунктчасында каралган документны 2023 елда формалаштыру, «Навигатор» кулланып электрон документ формасында формалаштыруның техник мөмкинлеге

булмаган очракта, кәгазьдә гамәлгә ашырыла.

9. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә әлеге карарга 3 кушымтада күрсәтелгән социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтү механизмнарын апробацияләү кысаларында үткәрелә торган чараларны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләре база зурлыкларының санлы кыйммәтләрен һәм максатчан ориентирларын билгеләү социаль хезмәтләр базарының конкуренция һәм өлгерү дәрәҗәсен фактор буенча анализлау юлы белән, Россия Федерациясе финанслар министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән методология нигезендә 2023 елның 1 ноябренә кадәр башкарыла.
10. Әлеге карарны «Интернет» челтәрендә веб-адрес буенча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Алабуга муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.
11. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Н.Д. Курамшинга йөкләргә.

Җитәкче | ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ | Э.Р. Әхмәдиева

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
14.12.2023 2023 номерлы
карарына 1 нче кушымта

**«Социаль өлкәдә дәүләт (муниципаль) хезмәте күрсәтүгә дәүләт (муниципаль) социаль заказы турында» 2020 елның 13 июлендәге 189-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы 2 өлеше 1 пунктында каралган хезмәт күрсәтүләрне башкаручыларны сайлап алу ысулын апробацияләү гамәлгә ашырыла торган муниципаль хезмәтләр исемлеге**

1. Өстәмә гомуми үсеш программаларын гамәлгә ашыру:

8042000.99.0.ББ52АЕ04000
(Техник юнәлеш, уку формасы көндезге;
сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балалардан тыш укчылар);
8042000.99.0.ББ52АЕ05000
(Техник юнәлеш, уку формасы көндезге;
сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балалардан тыш, дистанцион белем технологияләрен кулланып);
8042000.99.0.ББ52АЕ28000
(Табигый фән юнәлеше, уку формасы көндезге;
сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балалардан тыш укчылар);
8042000.99.0.ББ52АЕ29000
(Табигый фән юнәлеше, уку формасы көндезге;
сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балалардан тыш, дистанцион белем технологияләрен кулланып);
8042000.99.0.ББ52АЕ52000
(Физкультура-спорт юнәлеше, уку формасы көндезге;
сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балалардан тыш укчылар);
8042000.99.0.ББ52АЕ53000
(Физкультура-спорт юнәлеше, уку формасы көндезге;
сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балалардан тыш, дистанцион белем технологияләрен кулланып);
8042000.99.0.ББ52АЕ76000
(Сәнгать юнәлеше, уку формасы көндезге;

сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балалардан тыш укчылар);
8042000.99.0.ББ52АЕ77000
(Сәнгать юнәлеше, уку формасы көндезге;
сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балалардан тыш, дистанцион белем технологияләрен кулланып);
8042000.99.0.ББ52АЖ00000
(Туристлык-туган якны өйрәнү юнәлеше, уку формасы көндезге; сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балалардан тыш укчылар);
8042000.99.0.ББ52АЖ01000
(Туристлык-туган якны өйрәнү юнәлеше, уку формасы көндезге; сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балалардан тыш, дистанцион белем технологияләрен кулланып);
8042000.99.0.ББ52АЖ24000
(Социаль-педагогик юнәлеш, уку формасы көндезге;
сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балалардан тыш укчылар);
8042000.99.0.ББ52АЖ25000
(Социаль-педагогик юнәлеш, уку формасы көндезге;
сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балалардан тыш, дистанцион белем технологияләрен кулланып);

## Алабуга муниципаль районы буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру механизмнарын апробаци

| № | Максат | Индикатор тибы | Индикатор | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | | | |
| 1. | Коммерциясез оешмалар тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен шартларны яхшырту | Процесс | Социаль өлкә тармакларында дәүләт ярдәме күрсәтелә торган ( салым ташламалары һ. б.) муниципаль хезмәтләр күрсәтүче ком оешмаларның гомуми саны, берәмлекләр[3 | | | |
| | | Арадаш нәтиҗә | Социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүче коммерциясе гомуми саны, берәмлекләр | | | |
| | | Йомгаклау нәтиҗәсе | 189-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру механизмнарын апробацияләү өчен (алга таба – апробация) сайлап алынган социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүче коммерциясез оешмалар саны, берәмлекләр | зурлык:<br>ел: 2023 | зурлык:<br>ел: 2024 | «ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | | алардан дәүләт ярдәме күрсәтелә торган коммерциясез оешмалар саны (шул исәптән укыту, салым ташламалары һ. б.), берәмлекләр | зурлык:<br>ел: 2023 | зурлык:<br>ел: 2024 | Эшче төркем әгъзалары |
| 2. | Муниципаль булмаган хезмәтләр башкаручыларны сайлаганда конкуренцияне көчәйтү | Процесс | 189-ФЗ номерлы Федераль законда каралган механизмнарны исәпкә алып, җирле үзидарә органнары актларын төгәлләштерү/эшләп бетерү | зурлык:<br>ел: 2023 | зурлык:<br>ел: 2024 | «ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Арадаш нәтиҗә | Социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтү максатларында социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүчеләрне сайлап алу процедураларында катнашкан, социаль өлкәдә апробация өчен сайлап алынган юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, физик затлар - товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләр (алга таба – хезмәтләр башаруычылар) саны | зурлык:<br><br>ел: 2023 | зурлык:<br><br>ел: 2024 | «ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | | алардан социаль сертификат нигезендә социаль өлкәдә муниципаль (муниципаль) хезмәтләр башкаручылар реестрына кертелгән апробация өчен сайлап алынган юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, физик затлар –товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүче саны | зурлык:<br><br>ел: 2023 | зурлык:<br><br>ел: 2024 | «ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | Йомгаклау нәтиҗәсе | социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтү максатларында хезмәтләрне башкаручыларны сайлаганда муниципаль учреждениеләр белән конкуренция өчен югары дәрәҗәдәге потенциалга ия булган дәүләт яки муниципаль учреждениеләр булмаган юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең, физик затларның – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләрнең апробация өчен сайланган күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтүче оешмаларның гомуми күләмендә өлеше | зурлык:<br><br>ел: 2023 | зурлык:<br><br>ел: 2024 | «ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| 3. | Хезмәтләргә җәлеп итүне/хезмәтләрдән файдалана алуны арттыру | Процесс | Социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр кулланучылар (алга таба – хезмәтләр кулланучы) һәм хезмәтләр башкаручылар өчен мәгълүмати кампания | зурлык:<br><br>ел: 2023 | зурлык:<br><br>ел: 2024 | «ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | Арадаш нәтиҗә | Социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүче, апробация өчен сайлап алынган юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең, физик затларның - товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләрнең гомуми саны, берәмлекләр | зурлык:<br><br>ел: 2023 | зурлык:<br><br>ел: 2024 | «ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | алардан дәүләт яки муниципаль учреждениеләр булмаган юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, физик затлар - товарлар, эшләр, хезмәтләр, җитештерүчеләр саны, берәмлекләр | зурлык:<br><br>ел: 2023 | зурлык:<br><br>ел: 2024 | «ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | Йомгаклау нәтиҗәсе | Апробация өчен сайланган социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр кулланучыларның гомуми саны, кеше | зурлык:<br><br>ел: 2023 | зурлык:<br><br>ел: 2024 | «ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | | Дәүләт яки муниципаль учреждениеләр булмаган хезмәтләр башкаручылардан апробация өчен сайланган социаль өлкәдә дәүләт хезмәте алган хезмәтләр кулланучылар саны, кеше | зурлык:<br><br>ел: 2023 | зурлык:<br><br>ел: 2024 | «ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| . | Күрсәтелгән хезмәтләрнең сыйфатын арттыру | Процесс | Апробация өчен сайланган социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтү стандартларын (тәртипләрен) һәм аларны күрсәтү сыйфатына минималь таләпләрне билгеләү | зурлык:<br><br>ел: 2023 | зурлык:<br><br>ел: 2024 | «ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | Процесс | Апробация өчен сайланган социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын мониторинглау һәм бәяләү системасын (шул исәптән мөмкинлек булганда мәгълүмат системасын) булдыру | зурлык:<br><br>ел: 2023 | зурлык:<br><br>ел: 2024 | «ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Процесс | Апробация өчен сайланган социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне җайга салучы муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында, аларны күрсәтү стандартына (тәртибенә) нигезендә мондый хезмәтләр күрсәтүне мониторинглаучы структур бүлекчә (алга таба – структур бүлекчә) булу, шулай ук күрсәтелгән мониторингны үткәрү буенча чаралар исемлеге һәм мондый чараларны гамәлгә ашыру күрсәткечләре (алга таба – чек - бит) | зурлык: ел: 2023 | зурлык: ел: 2024 | «ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | Арадаш нәтиҗә | Социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүче, апробация өчен сайланган, социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтү стандарты (тәртибе) нигезендә мондый хезмәтләр күрсәтүне мониторинглаучы социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүче юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, физик затлар – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләр саны, берәмлекләр | зурлык: ел: 2023 | зурлык: ел: 2024 | «ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | Йомгаклау нәтиҗәсе | Апробация өчен сайланган социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне мониторинглау чаралары кысаларында күрсәтелгән структур бүлекчә үткәргән мониторинг барышында билгеләнгән күрсәткечләрнең чек-листка кертелгән күрсәткечләргә туры килү өлеше, процент | зурлык: ел: 2023 | зурлык: ел: 2024 | «ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| 5. | Социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүдән гражданнарның канәгать булуы арту | Процесс | Хезмәтләр башкаручыларның күрсәтелгән хезмәтләрне башкаручылар апробация өчен сайланган социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәткән хезмәтләр кулланучылар белән кире элемтә механизмнарын булдыру | зурлык: ел: 2023 | зурлык: ел: 2024 | «ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | Арадаш нәтиҗә | Апробация өчен сайланган социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләрне башкаручылар саны, күрсәтелгән башкаручылар апробация өчен сайланган социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәткән хезмәтләр кулланучыларның күрсәтелгән хезмәтләр сыйфатыннан канәгать булуына мониторинг үткәрә | зурлык: ел: 2023 | зурлык: ел: 2024 | «ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Йомгаклау нәтиҗәсе | Апробация өчен сайланган социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләрнең сыйфаты белән канәгать булган хезмәтләр кулланучыларның хезмәтләр башкаручылар тарафыннан канәгатьләнүләрен мониторинглау нәтиҗәләре буенча билгеләнгән, хезмәтләр кулланучыларның гомуми санынан проценты | зурлык:<br><br>ел: 2023 | зурлык:<br><br>ел: 2024 | «ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
14.12.2023 2023 14.12.2023
2023 карарына 2 нче кушымта

## Тукай муниципаль районы территориясендә социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру механизмнарын апробацияләү планы

| № | Апробация этабы | Чара | Башкару вакыты | Нәтиҗә | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | «Социаль өлкәдә муниципаль (муниципаль) хезмәт күрсәтүләргә дәүләт (муниципаль) социаль заказы турында» 2020 елның 13 июлендәге Федераль закон (алга таба – 189-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезләмәләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле оештыру чараларын үткәрү | 1.1. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – Бюджет системасының бердәм порталы) формалаштыруы 189-ФЗ номерлы Федераль закон белән каралган мәгълүмат һәм документларны Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә урнаштыруны оештыру | 2023 елның 15 декабре | Бюджет системасының Бердәм порталында мәгълүмат һәм документлар урнаштыру оештырылды | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты<br>«ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | 1.2. Хезмәтләр башкаручылар белән өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру буенча карарның 1 кушымтасы нигезендә килешү төзүне тәэмин итэ лектрон формада | 2023 елның 15 декабре | Башкаручылар һәм хезмәтләр белән электрон рәвештә килешү төзү тәэмин ителде | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты<br>«ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 2. | Норматив хокукый тәэмин итү | 2.1. Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль социаль заказлар формалаштыру тәртибен раслау, аларның үтәлеше турында хисап формалаштыру формасы һәм сроклары турында Алабуга муниципаль районы хакимиятенең норматив хокукый акты проектын эшләү | 2023 елның 15 декабре | Акт расланды | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты<br>«ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | 2.2. Социаль сертификат нигезендә социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә акчаларны яңадан бүлү өлешендә бюджет турында карарга/җыелма бюджет язуына үзгәрешләр кертү. Үзгәрешләр социаль заказ параметрларының башкарылган исәпләүләре нигезендә гамәлгә ашырыла | 2023 елның 15 декабре | Бюджет турындагы карарга / җыелма бюджет язмасы кертелде | ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының Финанс-бюджет палатасы |
| | | 2.3. Социаль сертификат нигезендә «Өстәмә гомуми үсеш программаларын гамәлгә ашыру» муниципаль хезмәтен башкаручылар реестрын формалаштыру тәртибен раслау турында Алабуга муниципаль районы хакимиятенең норматив хокукый акты проектын эшләү | 2023 елның 15 декабренә кадәр | Акт расланды | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты<br>«ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | 2.4. Алабуга муниципаль районы хакимиятенең «Өстәмә гомуми үсеш программаларын гамәлгә ашыру» муниципаль хезмәтен алуга социаль сертификатларны электрон рәвештә формалаштыру норматив хокукый акты проектын һәм аларны алучылар реестрын эшләү | 2023 елның 15 декабренә кадәр | Акт расланды | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты<br>«ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2.5. Социаль өлкәдә муниципаль хезмәт күрсәтүгә социаль сертификат нигезендә социаль өлкәдә муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) турында электрон формада килешүләр төзү һәм социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр башкаручы вәкаләтле орган исеменнән эш итәргә хокуклы затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалау кагыйдәләрен раслау турында Алабуга муниципаль районы хакимиятенең норматив хокукый акты проектын эшләү | 2023 елның 15 декабренә кадәр | Акт расланды | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты<br>«ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | 2.6. Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә социаль сертификат нигезендә социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү/каплау турында килешүгә түләүгә субсидия бирү тәртибен раслау турында Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы хакимиятенең норматив хокукый акты проектын эшләү | 2023 елның 15 декабренә кадәр | Акт расланды | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты<br>«ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | 2.7. Бер яки берничә вәкаләтле органнарның муниципаль социаль заказларына кертелгән һәм социаль сертификат нигезендә күрсәтелә торган социаль өлкәдә ике һәм аннан да күбрәк муниципаль хезмәтләр алуга ярдәм социаль сертификат бирү тәртибен раслау турында Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы хакимиятенең норматив хокукый акты проектын эшләү | 2024 елның IV кварталы | Акт расланды | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты<br>«ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | 2.8. Социаль өлкәдә хезмәт күрсәтүләрне башкаручыларны сайлап алу нәтиҗәләре буенча төзелә торган килешүнең типлаштырылган формасын раслау турында Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы финанс органы боерыгы проектын эшләү | 2023 елның 15 декабренә кадәр | Боерык расланды | ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының Финанс-бюджет палатасы |
| | | 2.9. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән, социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтү максатларында хезмәтләр башкаручы тарафыннан хезмәтләр кулланучы белән төзелә торган шартнамәгә кертелә торган башка шартлар турында Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы хакимиятенең норматив хокукый акты проектын эшләү | 2024 елның IV кварталы | Аклар проектлары эшләнде/ актлар расланды | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты<br>«ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Коммуникацион ярдәм | 3.1. Потенциаль хезмәт күрсәтүчеләр белән семинар - киңәшмә оештыру һәм үткәрү | Кимендә кварталга бер тапкыр (кирәк булган саен) | Киңәшмә үткәрелде | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты<br>«ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | 3.2. Социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру механизмнарын апробацияләүне гамәлгә ашыру (алга таба – апробация) турында материаллар әзерләү һәм мәгълүмати кампания үткәрү (массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек) | 2023 елның 15 декабренә кадәр | Материаллар әзерләнде | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты<br>«ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | 3.3. Апробациядә катнашу өчен кызыксынган яклар (шул исәптән хезмәтләр кулланучылар, муниципаль булмаган оешмалар һәм коммерциясез оешмалар вәкилләре, хезмәтләр кулланучылар белән турыдан-туры эшләүче вазыйфаи затлар һәм персонал) белән консультацияләр, семинарлар, киңәшмәләр үткәрү | кирәк булган<br>саен | Консультацияләр үткәрелде | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты<br>«ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | 3.4. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органының массакүләм мәгълүмат чараларында 189-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыруны яктырту буенча чаралар планын әзерләү | 2023 елның 1 ноябренә кадәр | Чаралар планы расланды | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты<br>«ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 4. | Башкаручылары хезмәтләр башкаручыларны сайлап алу нәтиҗәләре буенча билгеләнгән муниципаль хезмәтләр турында карар һәм хезмәтләр башкаручыларны сайлап алу ысулын сайлау | 4.1. «Өстәмә гомуми үсеш программаларын гамәлгә ашырумуниципаль хезмәтен күрсәтүгә муниципаль социаль заказны формалаштыру, раслау һәм урнаштыру | 2023 елның 1 ноябренә кадәр аннан соң ел саен 1 январьга кадәр | Муниципаль социаль заказ расланды һәм урнаштырылды | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты<br>«ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| 5. | Хезмәтләр башкаручыларны сайлап алу (хезмәтләр башкаручыларны сайлап алу ысулын сайлаган очракта) | 5.1. Башкаручылар реестрын формалаштыру (гариза буенча, нигез булып лицензия тора) | 2023 елның 25 октябренә кадәр | Реестр формалаштырылды | ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | 5.2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан 2023 елга расланган «Өстәмә гомуми үсеш программаларын гамәлгә ашыру» муниципаль хезмәтен күрсәтүгә муниципаль заказны үтәү максатларында социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә социаль сертификат нигезендә социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) турында килешүләр төзү | 2023 елның 25 октябренә кадәр | Килешүләр төзелде | ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | 5.3. «Өстәмә гомуми үсеш программаларын гамәлгә ашыру» муниципаль хезмәтен алуга социаль сертификатларны һәм аларны алучылар реестрын электрон рәвештә формалаштыруны тәэмин итү | 2023 елның 1 ноябренә кадәр | Сертификатлар формалаштырылды | ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | 5.4. «Өстәмә гомуми үсеш программаларын гамәлгә ашыру» муниципаль хезмәтен башкаручыларын сайлап алу | 2023 елның 15 декабренә кадәр | Сайлап алу үткәрелде | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты<br>«ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 6. | Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен мониторинглау һәм бәяләү системасы | 6.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен мониторинглау һәм бәяләү системасы мәсьәләләре буенча конференция оештыру | 2024 ел | Конференция үткәрелде | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты<br>«ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | 6.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен мониторинглау һәм бәяләү системасын эшләү | 2024 ел | Муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен мониторинглау һәм бәяләү системасы буенча методик тәкъдимнәр расланды | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты<br>«ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| 7. | Апробация нәтиҗәләрен бәяләү | 7.1. «Социаль өлкәдә дәүләт (муниципаль) хезмәтен күрсәтүгә дәүләт (муниципаль) социаль заказы турында» Федераль закон нигезендә социаль өлкәдә муниципаль (муниципаль) хезмәтләр күрсәтүне оештыру механизмнарын апробацияләү өлкәсе, чараларны гамәлгә ашыру турында мәгълүмат әзерләү | 2025 ел | Мәгълүмат тупланды, әзерләнде | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты<br>«ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | 7.2. Апробация нәтиҗәләре буенча расланган нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешүне бәяләү буенча киңәшмәдә катнашуны тәэмин итү | 2025 ел | Катнашу тәэмин ителде | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты<br>«ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |

[1] База зурлыгы күрсәткечен муниципаль социаль заказ формалашуның беренче елы буенча билгеләргә киңәш ителә.

[2] Максатчан ориентир күрсәткечен «Социаль өлкәдә муниципаль (муниципаль) хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт (муниципаль) социаль заказы турында» Федераль закон (алга таба – 189-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә социаль өлкәдә муниципаль (муниципаль) хезмәтләр күрсәтүне оештыру механизмнарын апробацияләү өлкәсендә хезмәттәшлек турында килешү гамәлдә булган соңгы ел өчен билгеләргә киңәш ителә.

[3] Әлеге таблица максатларында социаль өлкә тармакларында дәүләт хезмәтләренә 189-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы 2 өлеше нигезендә билгеләнгән эшчәнлек юнәлешләренә туры килгән дәүләт хезмәтләрен кертергә киңәш ителә.

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
14.12.2023 2023 номерлы
карарына 4 нче кушымта

## Алабуга муниципаль районы территориясендә социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру буенча эшче төркем турында Нигезләмә

### Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру буенча эшче төркем (алга таба – эшче төркем) Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы коллегиаль киңәшмә органы булып тора.

Эшче төркем, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында «Социаль өлкәдә дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүгә дәүләт (муниципаль) социаль заказы турында» 2020 елның 13 июлендәге 189-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясында билгеләнгән эшчәнлек юнәлешләренә туры килгән муниципаль хезмәтләр буенча (алга таба – 189-ФЗ номерлы Федераль закон) дәүләт социаль заказын формалаштыру буенча тәкъдимнәр әзерләгәндә, Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү максатында төзелгән.

Эшче төркем үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе законнарына, РФ субъекты законнарына, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль хокукый актларына, башка норматив хокукый актларга һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

Эшче төркем утырышлары нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарлар тәкъдим характерын йөртә.

### Эшче төркемнең бурычлары

Эшче төркемнең бурычлары булып тора:

189-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясында билгеләнгән эшчәнлек юнәлешләренә туры килгән муниципаль хезмәтләр буенча Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә дәүләт социаль заказын формалаштыру һәм раслау буенча тәкъдимнәр әзерләү.

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруның федераль законда каралган

механизмнарын апробацияләү өчен кирәкле чараларны гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр әзерләү.

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә муниципаль социаль заказны формалаштырганда һәм үтәгәндә Татарстан Республикасы дәүләт иәгълүмат системаларын куллану буенча тәкъдимнәр әзерләү.

Эшче төркем төзүнең әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатына ирешүгә юнәлтелгән башка бурычларны тормышка ашыру.

## Эшче төркемнең вәкаләтләре

Әлеге Нигезләмәнең 2 бүлегендә күрсәтелгән мәсьәләләрне хәл итү өчен эшче төркем түбәндәге вәкаләтләргә ия:

Эшче төркем утырышларында эшче төркем компетенциясенә кергән мәсьәләләрне карарга.

Җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан эшче төркем компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча мәгълүмат сорарга.

Эшче төркем бурычлары нигезендә җирле үзидарә органнары һәм оешмалары тәкъдим иткән мәгълүматны, документларны һәм материалларны карарга.

Җәмәгатьчелек башлангычларында белгечләрне, экспертларны, эксперт, фәнни, иҗтимагый һәм башка оешма вәкилләрен җәлеп итәргә.

Үз компетенциясе нигезләрендә җирле үзидарә органнарына тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр эшләргә.

## Эшче төркем функцияләре

Эшче төркемнең төп функцияләре булып түбәндәгеләр тора:

Федераль закон нигезендә социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру һәм федераль законда каралган социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру механизмнарын апробацияләүне үткәрү буенча эшче төркем әгъзаларының тәкъдимнәрен карау.

Апробация планын гамәлгә ашыру өчен кирәкле оештыру, методик, технологик чараларны формалаштыру, билгеләү.

Апробация планын гамәлгә ашыру барышына агымдагы мониторинг һәм контроль үткәрү.

## Эшче төркем эшчәнлеген оештыру

Эшче төркем составы Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

Эшче төркемне эшче төркем җитәкчесе җитәкли. Эшче төркем җитәкчесенең урынбасары бар. Эшче төркем җитәкчесе булмаган чорда

аның бурычларын җитәкче урынбасары башкара.

Эшче төркем җитәкчесе түбәндәге функцияләрне башкара:

эшче төркем эшчәнлеген оештыра;

эшче төркем эшчәнлеген планлаштыра;

эшче төркемнең чираттагы утырышында фикер алышу өчен көн тәртибен раслый;

эшче төркем утырышларын алып бара.

Эшче төркем утырышлары кирәк булганда үткәрелә.

Эшче төркем утырышы, әгәр анда эшче төркем әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, хокуклы дип санала.

Эшче төркем эшчәнлеген документаль тәэмин итүне эшче төркем секретаре башкара.

Эшче төркем секретаре:

эшче төркем утырышларын әзерләү һәм оештыруны гамәлгә ашыра;

эшче төркем карарлары проектларын әзерләүне гамәлгә ашыра;

эшче төркем утырышларының беркетмәләрен алып бара һәм проект комитетының беркетмә карарлары үтәлешен контрольдә тота;

эшче төркем утырышлары нәтиҗәләре буенча мәгълүмати материалларны, документларны гомумиләштерү һәм әзерләүне гамәлгә ашыра;

Эшче төркем карары, әгәр дә аның өчен эшче төркем әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булганда, эшче төркем җитәкчесе яки эшче төркем җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы эшче төркем җитәкчесе урынбасары тавышы хәлиткеч булып тора.

Эшче төркем карары эшче төркем утырышы беркетмәсе (алга таба – беркетмә) белән рәсмиләштерелә, ул эшче төркем җитәкчесе яки эшче төркем рәисе вазыйфаларын башкаручы эшче төркем җитәкчесе урынбасары тарафыннан имзалана.

Беркетмәләрнең күчермәләре эшче төркемнең барлык әгъзаларына җибәрелә.

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
14.12.2023 2023 номерлы
карарына 5 нче кушымта

**Алабуга муниципаль районы территориясендә социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру буенча эшче төркем составы**

| | |
|---|---|
| **Эшче төркем җитәкчесе**: | - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| **Эшче төркем җитәкчесе урынбасары:** | - «ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы |
| **Эшче төркем секретаре:** | - «ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ башлыгының тәрбия эшләре буенча урынбасары |
| **Эшче төркем әгъзалары**: | - «Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ рәисе (килешү буенча) |
| | - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы |
| | - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының спортны үстерү секторы мөдире |

Лист согласования к документу № 2023 от 14.12.2023
Инициатор согласования: Мусина Е.А. Главный специалист организационного отдела
Согласование инициировано: 18.12.2023 11:34

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано<br>18.12.2023 - 11:44 | - |